| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
| --- | --- | --- |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.04.2024 Казан ш. № 207-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының кайбер боерыкларына үзгәрешләре кертү турында

Законнарга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә боерам:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының кайбер боерыкларына кертелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары А.И. Галиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт
мөнәсәбәтләре
министрлыгының
11.04.2024 № 207-пр
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының кайбер боерыкларына кертелгән үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 21.06.2022 № 380-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга – күчемсез мөлкәт объектлары ияләренә арендага яки милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 05.09.2022 № 534-пр боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән):

Регламентка 3 нче кушымтаның 8 пунктында «төзелгән территориянең үсеше» сүзләрен «территориянең комплекслы үсеше» сүзләре белән алыштырырга;

Регламентка кушымтада (белешмәлек) “Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы” таблицасында «Җир ресурслары идарәсе башлыгы» дигән дүртенче юлны төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Дәүләт милкендәге җир кишәрлеген гражданинга яки юридик затка түләүсез милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 12.08.2022 № 496-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендәге җир кишәрлеген гражданинга яки юридик затка түләүсез милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 29.03.2023 № 212-пр, 26.09.2023 № 684-пр боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән):

Регламентка 1 нче кушымтаның 8 пунктында «торак төзелеше үсешенә ярдәм турында» сүзләрен «торак төзелеше үсешенә, туристлык инфраструктурасы объектлары булдыру һәм территорияләрнең башкача үсешенә ярдәм турында» сүзләре белән алыштырырга;

Регламентка 6 нче кушымтаның 8 пунктында «төзелгән территориянең үсеше» сүзләрен «территориянең комплекслы үсеше» сүзләре белән алыштырырга.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 11.05.2023 № 316-пр боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 26.09.2023 № 684-пр боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

Регламентка 1 нче кушымтаның 16 пунктында «торак төзелеше үсешенә ярдәм турында» сүзләрен «торак төзелеше үсешенә, туристлык инфраструктурасы объектлары булдыру һәм территорияләрнең башкача үсешенә ярдәм турында» сүзләре белән алыштырырга;

Регламентка 8 нче кушымтаның 8 пунктында «төзелгән территориянең үсеше» сүзләрен «территориянең комплекслы үсеше» сүзләре белән алыштырырга.

Регламентка 11 нче кушымтаның 1 пунктында «торак төзелеше үсешенә ярдәм турында» сүзләрен «торак төзелеше үсешенә, туристлык инфраструктурасы объектлары булдыру һәм территорияләрнең башкача үсешенә ярдәм турында» сүзләре белән алыштырырга;

Регламентка 12 нче кушымтаның 39 пунктында «торак төзелеше үсешенә ярдәм турында» сүзләрен «торак төзелеше үсешенә, туристлык инфраструктурасы объектлары булдыру һәм территорияләрнең башкача үсешенә ярдәм турында» сүзләре белән алыштырырга;

Регламентка 14 нче кушымтаның 16 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «16 | РФ ҖК 39⁶ 2 пунктының 13 подпункты | Арендага | Россия Федерациясенең Шәһәр төөзелеше кодексына туры китереп территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзелгән зат яки Россия Федерациясенең | Комплекслы үсеш турында шартнамә төзелгән территориянең чикләрендә ясалган җир кишәрлеге | * Территориянең комплекслы үсеше турында шартнамә яки карар<br>* Күчемсез милек объекты турында (соралган җир кишәрлеге турында) ЕГРНнан өземтә;<br>* Территориянең комплекслы үсеше турында шартнамә яки карар<br>* Күчемсез милек объекты турында (соралган җир кишәрлеге турында) |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Шәһәр төөзелеше кодексына туры китереп территориянең комплекслы үсеше чишелешен гамәлгә ашыруны тәэмин итүче юридик зат | | ЕГРНнан өземтә;<br>* Расланган планировка проекты һәм территорияне ызанлауның расланган проекты;<br>* Расланган планировка проекты һәм территорияне ызанлауның расланган проекты;<br>* Гариза бирүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә». |